МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

28.09.2020 г.Казань № 672

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2020 елның 19 октяберендә 6883 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 12 ноябрендәге 831 номерлы "Гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль хезмәт күрсәтүчеләрнең социаль хезмәтләрне күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында" карары белән расланган Гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль хезмәт күрсәтүчеләрнең социаль хезмәтләрне күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 12 ноябрендәге 831 номерлы "Гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль хезмәт күрсәтүчеләрнең социаль хезмәтләрне күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында" карары белән расланган Гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль хезмәт күрсәтүчеләрнең социаль хезмәтләрне күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган китерелгән үзгәрешләрне (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 04.02.2016 елның 61 номерлы, 11.12.2017 елның 863 номерлы, 16.07.2018 елның 561 номерлы, 12.10.2018 елның 938 номерлы, 20.05.2019 елның 380 номерлы, 14.11.2019 елның 1024 номерлы, 29.06.2020 елның 464 номерлы боерыкларында кертелгән үзгәрешләр белән) расларга.

Министр вазыйфасын башкаручы Э.А.Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт,
халыкны эш белән тәэмин итү һәм
социаль яклау министрлыгының
2020 елның 28 сентябрендәге 672
номерлы боерыгы белән расланган

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының
2015 елның 12 ноябрендәге 831 номерлы "Гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль хезмәт күрсәтүчеләрнең социаль хезмәтләрне күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында" карары белән расланган Гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль хезмәт күрсәтүчеләрнең социаль хезмәтләрне күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәреш

2.14 пунктның «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәтен күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһаз, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган биналар һәм корылмаларда гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла. Көтү залларында (биналарда) әлеге Регламентның 1.4.2 пунктындагы 1 пунктчасында каралган белешмәләр, шулай ук аларны тутыру үрнәкләре белән дәүләт хезмәте күрсәтү турында гарызнамә формалары урнаштырылган мәгълүмати стендлар җиһазландырыла.

Законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләр нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтелгән объектлардан (алга таба – объект) файдалану өчен инвалидларга түбәндәге шартлар тудыру тәэмин ителә:

а) объектларга тоткарлыксыз керү һәм алардан чыгу мөмкинлеге;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү урынына керү максатларында объект территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүче объектның хезмәткәрләре, ассистив һәм ярдәмче технологияләр, шулай ук алмаштырылган кресло-коляска ярдәмендә;

в) объектка кергәндә транспорт чарасына утыру һәм төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска файдаланып һәм, кирәк булганда, объектның хезмәткәрләре ярдәмендә;

г) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функцияләре тотрыклы бозык булган инвалидларны объект территориясе буенча озата бару;

д) объектка кергәндә һәм аннан чыкканда инвалидка ярдәм итү, инвалидка җәмәгать транспортының мөмкин булган маршрутлары турында мәгълүмат бирү;

е) инвалидларның объектка һәм дәүләт хезмәте күрсәтүләргә каршылыксыз керүен тәэмин итү өчен кирәкле мәгълүматны аларның тормыш эшчәнлеге чикләнүен исәпкә алып урнаштыру, шул исәптән дәүләт хезмәтләрен алу өчен

кирәкле тавыш һәм күрү мәгълүматын, шулай ук язу, билге һәм башка текстлы һәм график мәгълүматны контрастлы яссылыкта башкарылган Брайльнең рельефлы-нокталы шрифтындагы тамгалар белән кабатлау;

ж) махсус укытылуын раслый торган, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 22 июнендәге 386 номерлы боерыгы (Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы тарафыннан 2015 елның 21 июлендә теркәлгән, теркәү номеры 38115) белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелгән документ булган очракта, объектка озата баручы этләр белән кертелүне тәэмин итү.

Законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләр нигезендә инвалидларга дәүләт хезмәтләреннән файдалану өчен түбәндәге шартлар тудыру тәэмин ителә:

а) инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтү кагыйдәләре турында, шул исәптән дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү турында, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка гамәлләрне башкару турында үзләре өчен аңлаешлы формада мәгълүмат алу өчен кирәкле ярдәм күрсәтү;

б) ишетү буенча инвалидларга, кирәк булганда, рус ым-ишарә телен кулланып дәүләт хезмәте күрсәтү, шул исәптән объектка сурдотәрҗемәче, тифлосурдотәрҗемәче кертүне тәэмин итү;

в) инвалидларга башка затлар белән бертигез рәвештә дәүләт хезмәтен алырга комачаулаучы каршылыкларны җиңүдә башка төрле ярдәмне күрсәтү;

г) дәүләт хезмәт күрсәтү тәртибе турындагы документ, белдерү һәм күрсәтмәләрнең (шул исәптән мәгълүмати стендта) рельефлы-нокталы Брайль шрифтында һәм контрастлы фонда башкарылган күчермәләренең, шулай ук теркәү бүлегендә аудиоконтурының булуы.

Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектлардан инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү өлешендә таләпләр 2016 елның 1 июленнән соң файдалануга тапшырылган яисә реконструкцияләнгән, яңартылган объектларга һәм чараларга карата кулланыла».